| ГЛАВА КУШМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОШМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.11.2022 ел Кошман ав. № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең Урсак урман хуҗалыгы посёлогында гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2022 елның 26 ноябренә 10 сәг 00 минутка Урсак урманчылыгы посёлогы, Камал ур, 17 йорт адресы буенча урнашкан Урсак урманчылыгы конторасы бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең Урсак урман хуҗалыгы посёлогында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге территориясенә кергән Урсак урман хуҗалыгы посёлогында яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

а) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу».

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Кошман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән әлеге карарны игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырырга (http://pravo.tatarstan.ru). Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://kushman-kaybici.tatarstan.ru.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык Л.Р. Сафина